Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Яңгул авылы торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 ноябрь 2022 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Яңгул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешенең, түбән керемле (80 яшькә җиткән) ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерлардан, онкология авыруларыннан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым суммасының 90% ы күләмендә ташламалар бирү белән, 2023 елда үзара салым акчасын 1300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Яңгул авылы урамнарын тәртипкә китерү;

- Яңгул авылындагы хәрби-патриотик клуб бинасына капиталь ремонт буенча проект – смета документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасын үткәрү;

- Яңгул авылы, Таулы урамы, мәктәпкә керү юлларына асфальт салуны дәвам итү һәм асфальт – бетон өслекле чокырларны ямау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Габдрахманов